| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 03 2021 ел Болгар ш. № 155

ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 11 октябрендәге 712 номерлы карары белән расланган гражданнар милкенә муниципаль торак фондының торак урыннарын тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнар нигезендә туры китерү максатларында, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 октябрендәге 712 карары белән расланган гражданнар милкенә муниципаль торак фондының торак урыннарын тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 2.5 пунктының бишенче абзацын төшереп калдырырга;

1.2. Административ регламентның 2.6 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яшәү урыны буенча теркәү турындагы белешмәләрне - Эчке эшләр министрлыгы»;

1.3 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4-8 пунктчалар өстәргә:

«4) Граждан хәле актларын теркәү органнары-14 яше тулмаган гариза бирүченең гаилә әгъзалары өчен бала туу турында таныклык;

5) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никах төзү турындагы таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

6) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

7) Никахны өзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

8) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия ПФР».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www. spasskiy.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе В. А. Осокин